| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**02.07.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1765** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 3925 номерлы карары белән расланган Яшь гаиләне торак урынына мохтаҗ һәм (яисә) «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проектында катнашучы дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында» 236 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 3925 номерлы карары белән расланган Яшь гаиләне торак урынына мохтаҗ һәм (яисә) «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» төбәк проектында катнашучы дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2.2 пунктының унберенче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган рәсми мөрәҗәгатьне формат һәм логик яктан тикшерү орган (оешма) билгеле торган таләпләр нигезендә бердәм портал тарафыннан автоматлаштырып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы һәрбер юлын тутыру процессында башкарыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы рәсми мөрәҗәгать юлының дөрес тутырылмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерүнең тәртибе турында рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасының үзендә үк мәгълүмати хәбәр аркылы кисәтелә».

1.2. 2.16.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.16.4. Рәсми мөрәҗәгатьне формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) рәсми мөрәҗәгатьне һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәсен алу һәм саклау мөмкинлеге;

б) берничә мөрәҗәгать итүченең уртак рәсми мөрәҗәгатен җибәрүен күздә тоткан хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, берничә мөрәҗәгать итүче тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьнең бер электрон формасын тутыру мөмкинлеге;

в) рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

г) рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасына элек кертелгән билгеләрне, шул исәптән рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасына билгеләр кертүдә ялгышлар булганда һәм кабат кертү өчен әйләнеп кайтканда, кулланучы теләге буенча теләсә кайсы вакытта саклап калу мөмкинлеге;

д) мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәгълүматлар кертелгәнче электрон формадагы кырларны Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында булмаган белешмәләргә кагылышлы өлешендә бердәм порталда, хезмәт күрсәтү порталларында яисә рәсми сайтларда бастырып чыгарылган белешмәләрне, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмати системаларның мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасы" федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып тутыру (алга таба - идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасы);

е) рәсми мөрәҗәгатьнең электрон формасын тутырганда, элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, теләсә кайсы этапка әйләнеп кайту мөмкинлеге»;

1.3. 2.6.1.1 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгеләү шәхсән кабул итү барышында Россия Федерациясе законнары нигезендә Россия Федерациясе гражданы паспортын я шәхесне таныклаучы башка документны күрсәтү юлы белән яисә «Физик затларны биометрик персональ белешмәләр кулланып идентификацияләү һәм (яисә) аутентификацияләүне гамәлгә ашыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмати технологияләр кулланып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә идентификация һәм аутентификацияләү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин